| | |
|---|---|
| СОВЕТ РУССКО-АЗЕЛЕЕВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>РУС ӘҖИЛЕ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**2024 елның 11 марты** с.Русское Азелеево **№ 151**

Җир эшләрен башкаруга рөхсәт бирү буенча Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Рус Әҗиле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең вәкаләтләренең бер өлешен Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясының 4 өлешенә ярашлы рәвештә, Зеленодольск муниципаль районы Рус Әҗиле авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Җир эшләрен башкаруга рөхсәт бирү буенча Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы муниципаль берәмлегенә Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Рус Әҗиле авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең вәкаләтләренең бер өлешен тапшырырга.

2. Зеленодольск муниципаль районы Рус Әҗиле авыл җирлеге башкарма комитетына Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты белән килешү төзергә.

3. Вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыру өчен ел саен Рус Әҗиле авыл җирлеге бюджетыннан Зеленодольск муниципаль районы бюджетына бирелә торган бюджетара трансфертлар хисабына башкарыла.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында игълан итәргә (http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр порталының Интернет челтәрендә (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук Рус Әҗиле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча: Рус Әҗиле авылы, Центральная урамы, 1йорт (җирлек администрациясе бинасы), Карәшәм авылы, Новая урамы, 27 йорт (мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Рус Әҗиле авыл җирлеге башлыгы**
**Совет рәисе** **Г.Ф.Семахина**